ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.08.2023 Олы Кайбыч ав. № 312

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 288 номерлы карары белән расланган спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 288 номерлы карары белән расланган спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.7.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7.1. Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) Регламентның 2.5 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә бирелергә тиешле документларны тапшырмау;

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соралган законлы вәкилләр турында белешмәләрнең расланмавы, гаризаны (гарызнамәне) вәкаләтле булмаган зат бирүе;

3) документларны тиешле булмаган органга тапшыру;

4) дөрес булмаган белешмәләр, килешмәгән төзәтмәләр, җитди зарарлаулар булган, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлату мөмкинлеге бирми торган документлар, көчен югалткан документларны тапшыру;

5) Регламент нигезендә муниципаль хезмәт алучы булмаган затның муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе;

6) гаризаның электрон формасында мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау, гаризаның электрон формасында һәм тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр булу;

7) гариза (гарызнамә) һәм электрон рәвештә башка документлар гамәлдәге законнарны бозып электрон имза белән имзаланган;

8) электрон документларны укып булмый.»;

1.2. 3 бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлектә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтүнең гомуми билгеләре белән берләштерелгән гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә, шул исәптән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган вариантлары булырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесенең
беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллина